ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА УРУССУ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы,
Пушкин урамы, 38

Тел.: 8(85593)2-92-40, факс: 2-61-50, e-mail: Pgt.Urussu@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 24 » 01 2024 ел № 3

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын (бер тапкыр түләүләрен) җыю тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге Уставы, 2020 елның 9 октябрендәге Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советының 7 санлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында»гы нигезләмә нигезендә, 2023 елның 14 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлегендә 2024 елда үзара салым акчаларын (бер тапкыр түләүләрен) кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 1 санлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» башкарма комитеты к а р а р итте:

1. Кушымталарны расларга:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын (бер тапкыр түләүләрен) җыю тәртибе (1 нче кушымта);

- Гражданнарның үзара салым акчаларын (бер тапкыр түләүләрен) түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы (2 нче кушымта);

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» Башкарма комитетының 2023 елның 1 февралендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын

(бер тапкыр түләүләрен) җыю тәртибен» раслау турында»гы 5 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.Н. Захаров

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
«шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе»
Башкарма комитетының
2024 елның «_24__»__01______
__3__санлы карарына 1 кушымта

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын (бер тапкыр түләүләр) җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын (бер тапкыр түләүләр) җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган гражданнар, гражданнар җыенында катнашу-катнашмауларына һәм тавыш бирүдә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 2024 елның 1 апреленә кадәр үзара салым акчалары түләүне башкарыла.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын (бер тапкыр түләүләр) түләүдән азат ителә:

а) Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгән кешеләр;

б) Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары;

в) Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр;

г) 1,2 төркем инвалидлар, балачактан инвалидлар;

д) 80 яшьтән өлкәнрәкләр;

е) Чернобыль АЭСында аварияне бетерүчеләр һәм аларга тиңләштерелгән гражданнар категорияләре.

4. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән көндезге уку формасы студентлары өчен үзара салым акчаларын (бер тапкыр түләүләр) түләү 200 сум күләмендә билгеләнә.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (искәртү) бланкы гражданнарга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (искәртүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын (бер тапкыр түләүләр) күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар (бер тапкыр түләүләр) Федераль казначылыкның ТР буенча идарәсе (Ютазы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы) шәхси счетына керә.

7. Гражданнарның үзара салым акчаларын (бер тапкыр түләүләрен) түләү физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны, почта күчерүләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Башкарма комитеты кассасы аша яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша сылтама буенча башкарыла https://uslugi.tatarstan.ru/.

8. Гражданнарның үзара салым акчаларын (бер тапкыр түләүләр) түләү фактын гражданнарның үзара салым акчаларын (бер тапкыр түләүләр) түләү турында хәбәрнамә (искәртү), керем касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар раслый.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары (бер тапкыр түләүләр) законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
«шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе»
Башкарма комитетының
2024 елның «_24_»__01______
_3___санлы карарына 2 кушымта

**Гражданнарның үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында**
**____ санлы**
**Хәбәрнамә (искәртү)**

Түләүченең Ф.И.А. ______________________________________________
________________________________________________________________
Адрес: __________________________________________________________
______________________________________________________________нигезендә
Сезгә_____________________кадәр, _______________________________________
________________________________________________________________
чараларын гамәлгә ашыру өчен үзара салым буенча бер тапкыр түләү тәләргә кирәк:
_____________ сум,
Түбәндәге реквизитлар буенча:
алучы банкы БИК _________________________________
Сч. № ______________________________________________
Б/С _________________________________________________
ИНН ________________________________________________
КПП ________________________________________________
КБК ________________________________________________
ОКАТО ______________________________________________
Түләүнең билгеләмәсе______________________________________________
________________________________________________________________
Җитәкче _________________ _____________________________________
П.У. (имза) (имзаны раслау)
**- - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - -**

Гражданнарның үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (искәртү) _________________сум.

Түләүченең Ф.И.А.__________________________________________________
________________________________________________________________
Адрес: __________________________________________________________
________________________________________________________________
«____» _____________ 20__елны _________________________________________алдым
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхси тапшырылган очракта, өземтә (корешок) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.*